**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

"17" гыйнвар 2019 ел №2

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 18нче номерлы«Физик затлар мөлкәтенә салым турында "гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеш), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы КАРАР кылды:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 204 елның 10 ноябрендәге 18 нче номерлы«Физик затларның милкенә салым турында» гы карарына түбәндәге узгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3.1 һәм 3.2 пункт өстәргә:

«3.1.18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан күбрәк балалары булган физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү.

3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә. Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына карамастан салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, бер өлеше фатир яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында күрсәтелгән бина яки корылма;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 15 пунктчасында күрсәтелгән хуҗалык төзелеше яисә корылмасы;

5) гараж яки машина-урын.

Салым ташламасы, салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннардан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 406налы статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми.».

2. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 ноябрендәге 35 номерлы«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 18 нче номерлы «Физик затларның милкенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында " карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Юбилей урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 56а йорт адресы

буенча урнашкан махсус мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы хокукый рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Актаныш авыл җирлеге»бүлегендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш авыл жирлеге
Советы рәисе

Э.Н.Фәттахов